Раслыйм:
«Сәләт» ТРЯИФ
Генераль директоры
Ж.Ш. Сөләйманов
______________
«22» март 2018 ел.

2018 елда Сәләтнең җәйге профильле сменаларында катнашу өчен грант алуга чит илләрдә яшәүче ватандаш балалар һәм яшләр өчен үткәрелә торган "Тулпар" конкурсы тәртипләре турында

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр.

2018 елда Сәләтнең җәйге профильле сменаларында катнашу өчен грант алуга чит илләрдә яшәүче ватандаш балалар һәм яшьләр өчен үткәрелә торган "Тулпар" конкурсы (моннан соң – Конкурс) Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов кушуы һәм ярдәме белән үткәрелә.

Конкурс Татарстан Республикасының «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды, Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә оештырыла.

2. Конкурсның максаты һәм бурычлары.

Бәйгенең төп максаты – чит илләрдә яшәүче ватандаш сәләтле балалар һәм яшьләрне Сәләт берләшмәсенең белем бирү мохитенә җәлеп итү.

Конкурсның бурычлары:

- чит илләрдә яшәүче ватандаш балалар һәм яшьләр өчен сыйфатлы ял оештыру;
- төрле илләрдә яшәүче балалар һәм яшьләргә үзара тыгыз мөнәсәбәтләр тудыру һәм дуслашырга, алга таба да аралашырга ярдәм итү;
- балалар һәм яшьләрне татар халкы һәм Татарстанда яшәүче башка халыкларның милли гореф-гадәтләре, мәдәнияте белән таныштыру;
- татар телендә аралашу өчен шартлар тудыру, татар телен өйрәнүдә булышу;

- балалар һәм яшьләрне Татарстанда уздырыла һәм чынга ашырыла торган, аеруча алар катнаша алырлык актуаль проектлар белән таныштыру;
- чит илләрдә яшәүче ватандаш балалар һәм яшьләргә Татарстанга карата уңай фикер һәм дустанә мөнәсәбәт тудыру, Татарстан турында белемнәрен арттыру;
- балалар һәм яшьләрне Татарстанда шәхес буларак һәм профессиональ үсеш өчен булган мөмкинлекләр белән таныштыру.

3. Конкурсны үткәрү вакыты һәм урыны.

1-нче этап – «Читтән торып сайлап алу этабы»: Конкурста катнашу өчен www.selet.biz сайтында гариза тутырырга һәм видео яздырып (2 минуттан артык булмаска тиеш) аны **2018 елның 15 апреленә** кадәр seletvatandashlar@gmail.com электрон почтасына җибәрергә кирәк.

2-нче этап – «Турыдан-туры сайлап алу этабы»: **2018 елның 15 апреленнән алып 20 апреленә** кадәр 1-нче этапны уңышлы узган катнашучылар белән шәхси онлайн-әңгәмәләр уздырыла.

Конкурсның нәтиҗәләре **2018 елның 25 апреленнән** дә соңга калмый хәбәр ителәчәк.

4. Конкурсның катнашучылары.

Конкурсны уздыру вакытында якын һәм чит илләрдә яшәүче 12 яшьтән алып 18 яшькә кадәр ватандашлар катнаша ала.

Сайлап алу критерийлары:

- уку, фән, иҗат, спорт, иҗтимагый эшчәнлектә булган казанышлар;
- татар телен өйрәнү теләге;
- академик өлгереш;
- креативлык;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә (татар, рус теле) яки инглиз телендә (Сәләт мохите өч телле) ирекле сөйләшү.

5. Конкурсның җиңүчеләре.

Конкурсның җиңүчеләре булып сайлап алу этаплары нәтиҗәләре нигезендә иң күп балл җыйган катнашучылар санала. Конкурсның җиңүчеләренә яшәгән шәһәреннән алып Казанга кадәр һәм кире якка юл чыгымнарын каплау, Казан шәһәре

буенча экскурсия  программасы һәм Сәләтнең җәйге профильле сменаларының берсендә катнашу өчен грант бирелә.

## 6. Конкурсның Оештыру комитеты.

Оештыру комитеты составына Сәләт клублары әгъзалары керә. Оештыру комитеты исемлеге «Сәләт» ТРЯИФ генераль директоры тарафыннан раслана. Оештыру комитеты Конкурсны әзерләү һәм үткәрүне үз өстенә ала һәм шулай ук җиңүчеләр белән килешү нигезендә, алар катнашачак Сәләт сменасын билгели.

Оештыру комитеты Сәләт йортында (Казан шәһәре, Островский ур., 23 йорт) урнашкан.

## 7. Конкурсның Экспертлар советы.

Конкурсның этапларын үткәрү, аларга бәя бирү өчен Экспертлар советы төзелә. Экспертлар советы составын «Сәләт» ТРЯИФ генераль директоры раслый.

Экспертлар советы Татарстан Республикасы һәм Рәсәй Федерациясе хакимиятләре, Татарстан Республикасы һәм Рәсәй Федерациясе иҗтимагый оешмалары вәкилләреннән, җәмәгать эшлеклеләреннән туплана.

Конкурсның Экспертлар советы Конкурс материалларына бәя бирә, экспертиза үткәрә, җиңүчеләре хакында карарлар кабул итә.